# Эчтәлек


| | | |
|---|---|---|
| 1 | Аңлатма язуы | 2 |
| 2 | Ковробукның актуальлеге | 2 |
| 3 | Ковробукның максаты һәм бурычлары | 3 |
| 3.1 | Ковробукның максаты | 3 |
| 3.2 | Ковробукның бурычлары | 3 |
| 4. | Яшь үзенчәлеге | 3 |
| 5. | Көтелгән нәтиҗә | 3 |
| 6 | Уеннарны уйнау буенча күрсәтмәләр | 3 |
| 7 | Дидактик уен “Көз күчтәнәчләре” | 3 |
| | Дидактик уен “Бу нәрсә?” (2-3 яшьлекләр) | 4 |
| | Дидактик уен “Нәрсә качты?” (2-3 яшьлекләр) | 4 |
| | Үстерешле уен “Табышмак әйтәм-тап” (3-4 яшьлекләр) | 4 |
| | Дидактик уен “Куянны сыйла” (3-4 яшьлекләр) | 4 |
| | Сүзле уен “Кәрзин нәрсә белән тулган?” (5-6 яшьлекләр) | 4 |
| | Сүзле уен “Реклама яса” (5-6 яшьлекләр) | 4 |
| | Дидактик уен “Бер-күп” (6-7 яшьлекләр) | 5 |
| | Дидактик уен “Куянга яшелчә бир” (6-7 яшьлекләр) | 5 |
| | Бармак уены “Яшелчәләр” (5-6 яшьлекләр) | 5 |
| | Үстерешле уен “Кем беренче таный” (5-6 яшьлекләр) | 5 |
| | Үстерешле уен “Мин башлыйм, син дәвам ит!” (6-7 яшьлекләр) | 5 |
| 8 | Дидактик уен “Әкияттә кунакта” (5-6 яшьлеклек ) | 5 |
| 9 | Дидактик уен “Минем өем” (6-7 яшьлекләр) | 5 |
| 10 | Үстерешле уен “Кыргый һәм йорт хайваннары” (3-7 яшьлекләр) | 5 |
| 11 | Үстерешле уен “Чыпчык оясын эзли” (6-7 яшьлекләр) | 6 |
| 12 | Үстерешле уен “Бизәк яса” (4-5 яшьлекләр) | 7 |
| 13 | Кулланылган әдәбият | 8 |

## I. Аңлатма язуы

Без тирән үзгәрешләр һәм социаль – икътисади үзгәртеп корулар чорында яшибез. Белем бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең эше дә көннән-көн яңара. Без, педагоглар, яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, белем бирүнең нәтиҗәле алымнарын эзлибез. Тәрбия һәм белем бирү эшендә бертөрлелектән арына барып, Федераль белем бирү стандартларына җавап бирә торган яңа технологияләрне көннән – көн киңрәк кулланабыз.

Балаларны ана телендә дөрес итеп сөйләшү, аралашу, аларның бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү өчен мин ковробукта сүзле, дидактик, үстерешле уеннар оештырам. Алар балаларны кызыксындыра, актив сөйләмен үстерергә булыша.

Дидактик уеннар – балаларны уйланырга, эзләнергә, фикер тупларга, берләштерергә, күнекмәләрне, гадәтләрне тормышта кулланырга өйрәтүче һәм тәрбия бирүче көчле чараларның берсе. Дидактик уеннар аша бала күп яңа информация ала. Аз әзерлекле, актив булмаган балалар башта уенны читтән генә күзәтәләр, аннары әкренләп уенга катнашып китәләр. Дидактик уеннарның балаларга акыл тәрбиясе бирүдә дә роле зур. Уен вакытында баланың сөйләме үсә, сүз байлыгы арта. Чөнки бала бу чакта күпләр белән бәйләнешкә керә, яңадан-яңа сүзләр ишетә һәм үзе дә аларны куллана.

Уен вакытында бала предметларны чагыштырырга, охшаш һәм аерым якларын ачыкларга өйрәнә; предметларның үзенчәлекләре: төсе, зурлыгы, формасы, сыйфаты белән таныша. Соңыннан уенның эчтәлеге катлауландыра.

Үстерешле уеннар нәниләрнең төрле яктан үсүен тәэмин итә, иҗади мөмкинлекләрен, хыялларын баетуда, фикер активлыгы һәм зиһеннәрен үстерүдә ныклы этәргеч булып тора.

Сүзле уеннар тәрбия чарасы буларак отышлы, чөнки алар барышында күмәклек, дуслык, игътибарлылык, ярдәмләшү кебек матур сыйфатлар, шулай ук бала күңелендә туган телне ихтирам итү, үз милләте белән горурлану хисләре тәрбияләнә.

Коврубукта уеннар оештырганда заман таләпләрен исәпкә алып планлаштыру, кызыклы, нәтиҗәле итеп үткәрү өчен төрле алымнар уйлап табу отышлы була. Уеннар кызыклырак итеп оештырылса, аларның файдасы да зуррак. Балаларга яратмаган уенны көчләп тагарга ярамый. Уен – ул балаларны яхшырак аңлау, аларга тагын да ныграк якынаю чарасы да. Чөнки нәкъ менә уеннар вакытында тәрбияче һәр баланың нәрсәгә сәләтле булуын, аның оештыру мөмкинлекләрен яхшырак күрә ала, холкын, гадәтләрен күбрәк аңлый.

Коврубук мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләрендә эшләүче тәрбиячеләргә, логопед, музыка җитәкчеләренә адреслана. Коврубукта тәкъдим ителгән уеннар педагогларга балаларның көндәлек эшчәнлеген оештыруда, ана теленә мәхәббәт тәрбияләүдә, аны тирәнтен өйрәнүдә файдалы ярдәмлек булыр дип ышанам.

## II. Коврубукның актуальлеге

Балаларны үз ана телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү бүгенге көндә дә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Балаларның авазларны дөрес әйтеп, җөмләләрне дөрес төзеп, үзләренең уй - фикерләрен тиешле эзлеклелектә, ашыйкмыйча сөйли белүләренә ирешү өчен, коврубукта сүзле, үстерешле, дидактик уеннар оештыру уңай нәтиҗәләр бирә. Ул мәктәпкәчә яшьтәге балаларның танып белү эшчәнлеген, иҗади фикерләвен һәм сөйләмен үстерә, уенда бала үзе белмәгәнне өйрәнергә, аны эшләргә омтыла. Шуңа да эшчәнлек һәм режим вакытларында коврубукта уеннар кулланам.

Коврубукта уеннар оештыруның максаты сөйләм үстерү күнекмәләре бирү генә түгел, ә баланың мөмкинлекләренә игътибарлылык, күзаллау, фикерләү, хәтер үсешен тәэмин итүче буларак та бәяләнә.

## III. Ковробукның максаты һәм бурычлары

### 1. Ковробукның максаты:

Эшчәнлек һәм режим чорларында балаларны ана теленә өйрәтү буенча узган материалны ныгыту өчен дидактик һәм үстерешле уеннар куллану.

### 2. Ковробукның бурычлары:

***Үстерешле:***

Балаларның тәрбияче биремнәрен төгәл үтәү, сорауларга ашыкмыйча, эзлекле итеп җавап бирү сыйфатларын, иҗади активлыгын, логик фикерләү сәләтләрен, тышкы билгеләренә карап предметларны аера белү күнекмәләрен үстерү.

***Тәрбияви:***

Табигать байлыкларына соклана белү хисләре, тереклек ияләренә сак караш тәрбияләү.

***Белем бирү:***

Дидактик һәм үстерешле уеннар аша дөрес сөйләм формалаштыру, җөмләләрдә сүзләрне яраштырып һәм дөрес итеп төзергә өйрәтү эшен дәвам итү. Табигатьтәге күзге үзгәрешләр, көзге уңыш турындагы белемнәрен камилләштерү, әйләнә-тирә дөньядагы иң гади бәйләнешләрне билгеләргә өйрәтү эшен дәвам итү.

## IV. Яшь үзенчәлеге

Ковробук эшчәнлек һәм режим вакытларында 2-7 яшьлек балалар өчен кулланыла. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга үз туган телләренә мәхәббәт, кызыксыну тәрбияләүдә дидактик һәм үстерешле уеннарның йогынтысы бик зур. Нәкъ менә шушы яшьтәге балаларда уеннар аша туган телне өйрәнүгә кызыксыну барлыкка килә. Балаларның сәләтен дә шушы яшьтә ачуга мөмкинлек бик зур. Әлбәттә, әле бу яшьтә балаларны нәрсәгә булса да өйрәтү уеннарсыз барып чыкмаячак, алар уен аша гына тирә – юньне таный алалар.

## V. Көтелгән нәтиҗә

Ковробукта үстерешле һәм дидактик уеннар уздырганнан соң балаларда билгеле бер белемнәр, күнекмәләр, монологик һәм диалогик сөйләм, үз-үзеңә ышанучанлык, сәләтләрен ачыклау барлыкка килә, ана теле буенча белемнәре ныгытыла, сөйләм телләре үсә. Балалар эшләгән эшләренә бәя бирергә өйрәнә, аларда башкаларның хәленә керә белү, ярдәмләшү, игътибарлылык кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә. Уеннар ярдәмендә оялчан, кыюсыз, үз эченә бикләнгән балалар да активлаша.

## VI. Уеннарны уйнау буенча күрсәтмәләр

### 1.“Дидактик уен “Көз күчтәнәчләре”



**I вариант. Бу нәрсә?" дидактик уены** (2-3 яшьлекләр)
**Максат.** Балаларның яшелчәләр (помидор кишер, кыяр) турындагы белемнәрен ныгыту. Яшелчәләрне тышкы күренеше буенча аера белү осталыгын үстерү.
**Уен барышы.** Бала үзе теләгән яшелчәне ала һәм ковробукка куя, тәрбияче сорый:
-Бу нәрсә?
-Бу помидор (кишер, кыяр)
- Помидор (кишер, кыяр) нинди?
-Кишер (помидор, кыяр) кайда үсә?
-Син нәрсә яратасың?
**II вариант. "Нәрсә качты?" дидактик уены** (2-3 яшьлекләр)
**Максат.** Игътибар һәм хәтер сәләте тәрбияләү. Балаларда күңел күтәренкелеге булдыру.

**Уен барышы.** Балалар күзләрен йомалар. Тәрбияче бер яшелчә рәсемен качыра. "Нәрсә юк?" соравына балалар күзләрен ачып карыйлар һәм нәрсә юк икәнен әйтәләр.
**III вариант. "Табышмак әйтәм-тап" үстерешле уены** (3-4 яшьлекләр)
**Максат.** Балаларның яшелчәләр (помидор, кишер, кыяр, шалкан) турындагы белемнәрен ныгыту, фикерләү һәм уйлау сәләтләрен үстерү.
**Уен барышы.** Тәрбияче яшелчәләр турында табышмаклар әйтә, балалар җавабын таба һәм яшелчәләрне куянның кәрзиненә салып бара:

Итләч, йомры яшелен
Өзеп алдым, яшердем.
Гаҗәпләндем бераздан,
Кояшсыз да кызарган (помидор).

Кечкенә генә йорт,
Эче тулы корт (кыяр)

Җир астында алтын казык,
Без аны алдык казып (кишер).

Бабай чәчкән аны көзен,
Чыгара алмаган берүзе (шалкан)

**IV вариант. "Куянны сыйла" дидактик уены** (3-4 яшьлекләр)
**Максат.** Яшелчә исемнәрен (помидор, кишер, кыяр, шалкан) дөрес әйтә алуларына ирешү. Диалог төзү күнекмәләрен камилләштерү.
**Уен барышы.** Бала ковробукка кәрзин тоткан куянны куя, аның кәрзиненә яшелчәләр сала:
**-**Куян, мә кызыл помидор аша.
-Куян, мә яшел кыяр аша.
**V вариант. "Кәрзин нәрсә белән тулган?" сүзле уены** (5-6 яшьлекләр)
**Максат.** Балаларның яшелчәләр (кыяр, суган, помидор, кишер) турындагы белемнәрен ныгыту. Сөйләмдә "белән" дигән бәйлек сүзне куллана белү, исемнәрне күплек санда әйтү күнекмәләрен үстерү. Зирәклек, күзәтүчәнлек, тапкырлык тәрбияләү.
**Уен барышы.** Тәрбияче балаларга сөйли:
-Балалар бакчага килделәр. Ә бакчада яшелчәләр бик күп иде. Балалар моны күреп сөенделәр һәм кәрзиннәрен яшелчәләр белән тутырдылар. Ә сезнең кәрзиннәрегез нәрсәләр белән тулган? *(Бала ковробуктагы кәрзингә яшелчәләр сала).*
-Минем кәрзинем кыярлар (суганнар, помидорлар, кишерләр) белән тулган.
**VI вариант. Уен "Реклама яса"** (5-6 яшьлекләр)
**Максат.** Яшелчәләр турындагы белемнәрен системалаштыру, алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү. Яшелчә исемнәрен берлек һәм күплек санда дөрес әйтә алуларына ирешү.

**Уен барышы.** Бала үзе теләгән яшелчәне сайлап ала, ковробукка куя һәм аны мактап сөйли. Үрнәк: кыяр яшел төстә, озынча, тәмле. Ул түтәлдә үсә. Кыяр файдалы, аннан салат ясыйлар, аны тозлыйлар. Кыярны ашагыз, сәламәт булырсыз!

**VII вариант. Дидактик уен "Бер-күп"** (6-7 яшьлекләр)

**Максат.** Исемнәрне берлек һәм күплек санда дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү.

**Уен барышы.** Бала ковробукка бер һәм күп яшелчәләр куя, аларны берлек һәм күплек санда әйтә: кыяр-кыярлар, кишер-кишерләр.

**VIII вариант. Дидактик уен "Куянга яшелчә бир"** (6-7 яшьлекләр)

**Максат.** Балаларның ишетү һәм сорауларга тулы итеп җавап бирү осталыкларын, уйлау һәм фикерләү сәләтләрен үстерү.

**Уен барышы.** Бала тәрбияче биремнәрен үти, яшелчәләрне куянның кәрзиненә сала:
-Куянга 5 зур кәбестә бир.
-Кәрзиннән 3 кәбестәне ал, Куянга ничә кәбестә калды?
-Куянга 2 кәбестә, 3 кечкенә суган бир. Кәрзиндә барлыгы ничә яшелчә булды?

**IX вариант. "Яшелчәләр" бармак уены** (5-6 яшьлекләр)

**Максат.** Балаларның бармак мускулларын, сөйләм телләрен үстерү, яшелчә исемнәрен ныгыту.

**Уен барышы.** Бала яшелчәләрне һәр бармакка урнаштыра һәм сөйли:
Кыяр өлгерә, борыч кызара,
Кәбестә үсә, помидор пешә,
Суган, сарымсак әзер –
Тик җыеп кына өлгер.

**X вариант. Үстерешле уен "Кем беренче таный"** (5-6 яшьлекләр)

**Максат.** Балаларның үз җирлегендә үсә торган яшелчәләр, аларның файдалы яклары турындагы белемнәрен ныгыту

**Уен барышы.** Бер бала яшелчә билгеләрен әйтә, калганнары нинди яшелчә булуын ачыклый. Җавабы табылган яшелчәне ковробукка куеп бара. Үрнәк: ул яшел төстә, сусыл, озынча, түтәлдә үсә. Аннан салат ясыйлар, кышка банкаларга тозлап куялар. Ул нәрсә?

**XI вариант. Үстерешле уен "Мин башлыйм, син дәвам ит!"**
(6-7 яшьлекләр)

**Максат.** Балаларның үз җирлегендә үсә торган яшелчәләр турындагы белемнәрен ныгыту, хәтер һәм игътибар сәләте тәрбияләү.

**Уен барышы.** Тәрбияче коврукка яшелчәләрне берәмләп куя бара һәм башлый, бала дәвам итә:
Ган, ган – ачы суган.
Сак, сак – ачы сарымсак.
Ге, ге – сары бәрәңге.
Дер, дер – кызыл чөгендер.
Шер, шер – озынча кишер.
Рыч, рыч – бик тәмле борыч.
Яр, яр – яшел кыяр.

## 2. Үстерешле уен "Кыргый һәм йорт хайваннары"



**I вариант.** (3-4 яшьлекләр)

**Максат.** Йорт һәм кыргый хайваннарны танып белергә өйрәтү.

**Уен барышы.** Ковробукка йорт һәм кыргый хайван рәсемнәре куела. Балалар "Бу хайванның исеме ничек?", "Ул кайда яши?" сорауларына тулы җавап бирергә өйрәнәләр.

**II вариант.** (4-5 яшьлекләр)

**Максат.** Йорт һәм кыргый хайваннарны аера белергә өйрәтү.

**Уен барышы.** Ковробукка куелган рәсемнәр буенча йорт һәм кыргый хайваннарны аералар, алар турында сөйлиләр.

**III вариант.** ( 5-7 яшьлекләр)

**Максат.** Иҗади фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Уен барышы.** Ковробукка куелган сюжетлы рәсемнәр буенча тәрбияче 2-3 җөмләне башлый, балалар үзләре уйлап чыгарып дәвам итәләр.

**IV вариант.** ( 6-7 яшьлекләр)

**Максат.** Хайваннарның әнисен (баласын) дөрес итеп әйтергә өйрәтү, сүз байлыгын арттыру, сүзнең төзелеше өстендә эшләүне дәвам итү.

**Уен барышы.** Балалар ковробукка куелган рәсем аша бу рәсемдә нәрсәне күрүләрен сөйлиләр. Сораулар бирелә:

-Бу йорт (кыргый) хайванның исеме нинди аваздан башлана?

-Сүзнең уртасында (ахырында) нинди аваз ишетелә?

-Сүз ничә иҗеккә бүленә?

-Шул сүз белән җөмлә төзе.

## 3. Үстерешле уен "Чыпчык оясын эзли"

*(6-7 яшьлек балалар өчен)*




**Максат.** Пространствода ориентлаша алуларына, тәрбияче биремнәрен аңлап, дөрес итеп үти алуларына ирешү.



**I вариант.**

**Уен барышы.** Тәрбияче:


- Балалар, кошлар кешеләргә, табигатькә нинди файда китерә?

-Әйе, кошлар безгә бик кирәк. Алар һәрвакыт безнең яклауга һәм саклауга мохтаҗ. Әйдәгез, менә бу чыпчыкка булышыйк әле. Ул оясына биш йомырка салган булган. Оясыннан еракка очып киткән һәм адашкан. Ул уңга (сулга) 1 (2-4) шакмак һәм аска (өскә) 1 (2-4) шакмак төшсә (менсә), ничә йомырка таба?

**II вариант.** Кошка үз оясын табу өчен нинди юл үтәргә кирәк?

## 4. Үстерешле уен "Бизәк ясa"

*(4-5 яшьлек балалар өчен)*



**Максат.** Балаларны түгәрәк һәм квадрат формага бизәк төшерергә өйрәтү. Геометрик формалар **(**түгәрәк, квадрат, өчпочмак) турында белгәннәрен ныгыту, геометрик формалардан композиция төзү, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

**I вариант.**

**Уен барышы.** Зур картон түгәрәк һәм турыпочмаклыкка, төрле төстәге геометрик фигуралар куеп, бизәкләр ясыйлар.

**II вариант.** Геометрик фигуралардан композиция ясау, аның турында сөйләү.

Үрнәк: Мин квадрат һәм өчпочмаклардан өй төзедем. Өй зур, матур, биек. Өйнең түбәсе, стенасы, 3 тәрәзәсе бар.

## Кулланылган әдәбият:


Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова И.Җ. Хәбибуллина "Туган телдә сөйләшәбез", 2-3 яшь. Казан, 2012

Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова И.Җ. Хәбибуллина "Туган телдә сөйләшәбез", 3-4 яшь. Казан: Фолиант, 2013

Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова И.Җ. Хәбибуллина "Туган телдә сөйләшәбез", 4-5 яшь. Казан, 2013

З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева "Туган телдә сөйләшәбез", 5-7 яшь, Казан: Фолиант, 2012

М.Ф.Кашапова "Уйныйк әле, балалар", Казан РИЦ "Школа", 2017

З.М.Зарипова, Р.С. Исаева "Үстерешле уеннар", Казан, 2013

"Туган телдә сөйләшәбез" (2-7 яшь) сериясеннән таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр

Интернет-ресурстан алынган рәсемнәр.